**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Кәкре Елга авыл җирлеге Советы**

Кәкре Елга авылы № 126 «18» март 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга » авыл җирлегенең 18.07.2018 ел. № 96 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга » авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм муниципаль берәмлектә гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында ( 09.10.2018 № 108 карар редакциясендә)

Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» Федераль законның 22 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктының үз көчен югалтуын тану турында» 2018 елның 27 декабрендәге 528-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә миграция өлкәсендә һәм эчке эшләр өлкәсендә дәүләт идарәсен үзгәртеп коруга бәйле рәвештә»

Кәкре Елга авыл җирлеге Советы **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга » авыл җирлегенең18.07.2018 ел. № 96 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга » авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм муниципаль берәмлектә гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча Нигезләмәгә ( 09.10.2018 № 108 карар редакциясендә) 1.7 пунктының икенче абзацындагы "миграция өлкәсендә хокук куллану функцияләрен гамәлгә ашыра торган башкарма хакимиятнең федераль органы территориаль органы" сүзләрен «Эчке эшләр өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органы территориаль органы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo. tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.М.Мөхәммәтҗанов